КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 27 май г.Казань № 644

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 316 нчы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 316 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 26 гыйнвар, 20 нче; 2007 ел, 28 апрель, 149 нчы; 2008 ел, 28 гыйнвар, 38 нче; 2008 ел, 25 июль, 534 нче; 2009 ел, 5 март, 125 нче; 2009 ел, 8 май, 283 нче; 2010 ел, 10 декабрь 1033 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 1 июль, 533 нче; 2012 ел, 10 март, 205 нче; 2012 ел, 9 июнь, 503 нче; 2013 ел, 18 март, 175 нче; 2013 ел, 30 ноябрь, 946 нчы; 2014 ел, 18 апрель, 254 нче; 2014 ел, 1 ноябрь, 842 нче; 2015 ел, 2 октябрь, 736 нчы; 2016 ел, 23 март, 157 нче; 2016 ел, 28 июль, 523 нче; 2016 ел, 17 август, 568 нче; 2016 ел, 7 декабрь, 904 нче; 2016 ел, 22 декабрь, 971 нче; 2017 ел, 27 март, 188 нче; 2017 ел, 29 август, 611 нче; 2017 ел, 22 сентябрь, 711 нче; 2018 ел, 25 май, 398 нче; 2018 ел, 25 декабрь, 1215 нче; 2019 ел, 24 июнь, 509 нчы; 2019 ел, 25 июль, 619 нчы; 2019 ел, 13 ноябрь, 1038 нче; 2020 ел, 3 февраль, 68 нче; 2021 ел, 20 июль, 607 нче, 2021 ел, 17 ноябрь, 1095 нче, 2022 ел, 24 гыйнвар, 44 нче, 2022 ел, 21 апрель, 383 нче, 2022 ел, 16 август, 838 нче, 2023 ел, 2 март, 198 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктта:

икенче абзацта «3 675,5», «32,2» саннарын тиешенчә «4057,7», «35,5» саннарына алмаштырырга;

өченче абзацта «8 425,1» саннарын «9 301,5» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы турындагы нигезләмәдә:

1.1 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

1.5 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

3.3 пунктта:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«республика башкарма хакимияте органнары белән берлектә Татарстан Республикасы дәүләт программаларын, шул исәптән агросәнәгать комплексы тармакларын реструктуризацияләү һәм үстерү, авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек сыйфатын тәэмин итү программаларын, шулай ук аграр һәм җир үзгәртеп корулар мәсьәләләре буенча башка норматив хокукый актлар проектларын эшли һәм гамәлгә ашыра, чираттагы финанс елына Россия Федерациясе дәүләт программалары кысаларында чараларны финанслау күләмнәрен нигезләп заявкалар төзи, аларны гамәлгә ашыруда катнаша;»;

бишенче абзацка «, күпьеллык үсентеләр үстерү буенча» сүзләрен өстәргә;

унсигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

«хисап булдыру һәм аны Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгына тапшыру өчен агросәнәгать комплексы оешмаларының финанс-икътисадый торышы турындагы мәгълүматны законнарда билгеләнгән тәртиптә җыя, эшкәртә, анализлый;»;

егерме өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү, төбәк азык-төлек ресурсларын булдыру өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуларны үтәү, буенча товар җитештерүчеләр һәм әзерләү оешмалары эшчәнлеген җайга сала;»;

егерме алтынчы абзацта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына идарә итүгә дәүләт заказы составында» сүзләрен төшереп калдырырга;

утыз тугызынчы абзацта «азык-төлек белән үз-үзен тәэмин итәрлек» сүзләрен «азык-төлек иминлеге» сүзләренә алмаштырырга;

кырык өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«документларны карый һәм агросәнәгать комплексы объектларының, Министрлык эшчәнлеге өлкәсендә гамәлгә ашырыла торган масштаблы инвестиция проектларының, Татарстан Республикасы Җир кодексына кушымтада билгеләнгән критерийларга туры килүе турында дәлилләнгән бәяләмәләр проектларын, шулай ук мондый объектлар һәм проектлар параметрларына үзгәрешләр кертүнең максатка ярашлы булуы турында дәлилләнгән бәяләмәләр проектларын килештерә;»;

4.1 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга.

2. Бу карарның 1 пунктындагы икенче - дүртенче абзацлары гамәле 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин